| ГЛАВА<br>Крындинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кырынды авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2020 Кырынды авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 19 ноябрендә 15сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 19 ноябрендә 17 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 3 этабын 2020 елның 19 ноябрендә 19 сәг 00 мин билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

- 1 этап: Кырынды авылының Киров ур., Киров тык., Совет урамында  яшәүчеләр;
- 2 этап: Кырынды авылының К.Маркс ур., Полевая ур., Полевой тык. яшәүчеләр;
- 3 этап: Кырынды авылының Кооператив ур., К. Маркс тык. яшәүчеләр.

2. Гражданнар җыенына  чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырындыторак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белеем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кырынды авылындагы Советурамы юлы өчен вак таш сатып алу һәм җәю;
2. Кырынды авылында су алу скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу.
3. Беларус 82.1тракторына асылмалы җиһазлар (ротор чапкыч) сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кырынды авылында, Совет урамы, 33 нче йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлегекарарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга  (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукыймәгълүматрәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы И. И. Закиров